Мәгърифәтче Бубилар истәлегенә багышланган укучыларның төбәкара укулары

---

**Секция**: “Туган ягымда Буби мәдрәсәсе эзләре”.

**Тикшерү эше:** “Иж – Бубый” мәдрәсәсе: мәгърифәт үзәге һәм аның татар халкы тарихын һәм мәдәниятен үстерүгә керткән өлеше”.

**Укучының исем – фамилиясе, әтисенең исеме**: Бәшәрова Эльвина Олег кызы.
**Фәнни җитәкче турында мәгълүмат:** Төхвәтуллина Әлфирә Әхтәмҗан кызы, Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбенең I квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

**Эшне тәкъдим итүче оешманың тулы исеме:** Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль бюджетлы гомуми белем бирү учреждениесе Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе.
**Сыйныфы:** Рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 7 нче Б сыйныфы укучысы ( татар төркеме ).

**Иж – Бубый - 2014**

**План.**

I. Кереш өлеш.
1.Тарих битләреннән.
2. Мәдрәсә тарихына багышланган музей.
II.Төп өлеш.
1. Мәдрәсә турында хатирәләр:
а) Бубый мәдрәсәсенең элекке шәкерте Габдулла Мостакаев истәлекләре. Ташкент, 1966 нчы ел.
ә) Мәдрәсә мөдире Габдулла Бубый сүзләре.
2. Бубый мәдәрәсәсе шәкертләре. Аларның мәгариф һәм мәдәният үсешенә кертән өлешләре.
III. Йомгаклау өлеше.
Шигъри күчтәнәч. "Аң – белем таратучы". Гөлзада Әхтәмова. Алабуга – Исәнбай.

**I. Кереш өлеш.**

**Тарих битләреннән.**

Халкыбызның мәдәнияте тарихында мәдрәсәләр зур урын билиләр. XX гасыр башында халыкны аң - белемгә тартып, милләтебезнең зыялыларын үстереп, укыту - тәрбиянең куелышы һәм эчке тәртип ягыннан алдынгы саналган, бөтен Русиядә дан - шөһрәт казанган татар мәдрәсәләре берничә генә. Алар – Казанда «Мөхәммәдия», Оренбургта «Хөсәения», Уфада «Галия», Әгерҗе төбәгендә Иж - Бубый мәдрәсәләре.

Иж - Бубый мәдрәсәсенең тарихы шактый зур һәм бай. Ул элекке Вятка губернасы Сарапул өязе Әгерҗе волостеның Иж - Бубый авылында 1781 нче елда оештырыла. Мәдрәсәнең 2 уку бинасы, гомуми тулай торагы, бай китапханәсе була.

Башка татар мәдрәсәләре белән беррәттән, ул да XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында зур үзгәрешләр кичерә. 1907 нче елдан башлап, мәдрәсәдә аерым фәннәр буларак гарәп, фарсы, төрек, рус, француз телләре, тарих, политэкономия, арифметика, геометрия, физика, астрономия, география, ботаника, медицина, психология, педагогика алдынгы рус һәм Европа уку йортлары дәрәҗәсендә укытыла. Фәлсәфә, логика, әхлак, Коръән, хәдис, ислам тарихы өйрәтелә. Укыту расписание буенча алып барыла, дәресләр үткәрү өчен бүлмәләр җиһазландырыла; уку елы ахырында имтиханнар уздырыла. Шулай итеп, мәдрәсәдә 15 – 20 төрле фән укытыла. Уку бай һәм ярлы балалары өчен түләүсез була. Тәртипле Буби мәдрәсәсендә барлыгы ике тапкыр дәрес өзгәннәр: бу - Лев Толстой һәм Габдулла Тукай үлүе турындагы хәбәрләрнең мәдрәсәгә килеп җиткән көннәрендә.

Русиянең төрле почмакларыннан мәдрәсәгә укырга яшьләр килә. 1908 -1911 нче елларда биредә һәр елны 500 шәкерт белем ала. Буби мәдрәсәсен тәмамлаучы һәр шәкерт "Укытучы" таныклыгына да ия булган.

Мәдрәсәдә һәр атнада әдәби, фәнни кичәләр уздырыла. Алда әйтеп үткәнемчә, мәдрәсәнең бай китапханәсе, шулай ук махсус җиһазландырылган спорт мәйданчыгы була.

Мәдрәсәне тәмамлап чыгучылар тирән фикерле, белемле, киң мәгълүматлы шәхесләр булып формалаша. Шәкертләрдә милли хис, хөр фикер, милли горурлык тәрбияләү – мәдрәсә эшчәнлегенең төп юнәлешләреннән була. Иж - Бубый мәдрәсәсенең уңышларга ирешеп чәчәк ату елларында аның белән бертуган Габдулла һәм Гобәйдулла Бубыйлар җитәкчелек итә.

Бу авылда Русиядәге мөселман хатын - кызлар өчен иң беренче уку йортларыннан кызлар мәдрәсәсе дә эшли. Ул Мөхлисә Нигъмәтуллина - Бубый карамагында була. Кызлар мәдрәсәсе "Дәрелмөгаллимат", ирләр **м**әдрәсәсе "Дәрелмөгаллимин" дип йөртелгән.

Тарихта якты эз калдырган өч бертуган – Гобәйдулла, Мөхлисә, Габдулла Нигъмәтуллиннар тырышлыгы белән Бубый мәдрәсәсе Россия мөселманнарының гыйлем дәрәҗәсенә әверелә. Шулай итеп, Иж – Бубыйны чын мәгариф учагына әверелдерү өчен Бубыйларның һәрберсе җанын – тәнен кызганмый эшли.

Мәдрәсәнең күренекле мөгаллимнәре: Әминә Аппакова, Котдус Абдрахманов, Әхмәтхарис Сайманов, Нәҗип Думави һәм башкалар.

Мәдрәсәнең дөньяви юл белән алга атлавы патша хөкүмәтен борчуга сала. Танылган татар уку йортларыннан булган Иж - Бубый мәдрәсәсе 1911 нче елның гыйнварында Русия хөкүмәтенә каршы фикер таратуда һәм панисламизмда гаепләнеп, яптырыла. Җитәкчеләре, мөгаллимнәре кулга алына.

Иж - Бубый урта мәктәбенең ветеран укытучысы Рәмзия Хәлиуллина тырышлыгы белән 1989 нчы елда мәктәптә мәдрәсә тарихына багышланган музей ачыла.

Музейны оештыруда Иж - Бубый авыл халкы , Америкада яшәүче татар галиме Азаде - Айшә ханым Рорлих, галим якташыбыз Раиф Мәрдәнов , филология фәннәре докторы Диләрә Тумашева, заманында мәдрәсәдә укыткан мөгаллимнәрнең, белем алган шәкертләрнең балалары - оныклары - Габдулла Бубиның Ленинградта яшәгән кызы - мәрхүмә Ситдика Бубинская, Казанда яшәүче укытучы Аидә Тайсина, Оренбургтан укытучы Мәдинә

Рәхимкулова, Казаннан медицина фәннәре кандидаты Гөлнар Газизова һәм башкалар зур ярдәм итәләр.

**II. Төп өлеш.**

### Мәдрәсә турында хатирәләр.

Мадти яктан тәэминаты җәһәтеннән бу мәдрәсә башка татар уку йортлары арасында беренче урынны тота, әмма эчке тәртипләре белән заман таләпләренә җавап бирми. Төп сыйныфларның күпчелек шәкертләре, бу хәлдән һич тә канәгать булмыйлар, һәм, 1909 – 1910 нчы уку елы башында җыелгач, мәдрәсә идарәсенә түбәндәге таләпләрне куялар: дин дәресләренә сәгатьләр санын киметергә, кайбер мөгаллим һәм нәзирләрне чыгарырга, һәртөрле иске һәм кирәкмәгән традицияләрне саклауга юнәлтелгән чикләүләрне бетерергә һәм башкалар.

Мәдрәсәдән чыгарылганнарның күпчелек өлеше, Сарапул өязендәге “Бубый” мәдрәсәсенә укырга барырга булалар. Бу урта педагогик уку йорты, башлыча, татар җәдид мәктәпләре өчен укытучылар хәзерли. Үз вакытында ул иң алдынгы уку йорты санала. Шушы ук авылда хатын - кызлар өчен дә мәдрәсә була. Бубыйга укырга Россиянең иң ерак өлкәләреннән дә ( Ташкент, Алма - Ата, Пишпәк, Капал, Пржевальск, Төмән һ.б. ) киләләр.

Укыту өчен нигездә рус уку йортларының программалары кабул ителеп, педагогика һәм ислам дине гыйлемнәре өстәлә. Рус, гарәп, француз телләре укытыла. Төп фәннәрнең күбесе татар телендә алып барыла. Табигать фәннәре өчен бай булмаган аерым кабинет була. Дәресләр яхшы үтә, шәкертләр зур теләк белән укыйлар һәм бик дус яшиләр.

Мәдрәсәдәге эчке тәртипләрнең, шәкертләр тормышының оештырылуы ягыннан бу уку йорты “Хөсәения” мәдрәсәсеннән күпкә аерыла. Монда һәр уку елы башында үткәрелгән ачык тавыш бирү юлы белән сайланган шәкертләр комитеты була. Бу комитет шәкертләргә кагылышлы бөтен мәсьәләләр белән дә шөгыльләнә. Мәдрәсәнең мөдире Габдулла Бубый була. Ләкин ул шәкертләрнең эчке эшләренә бөтенләй катышмый диярлек. Вакыт - вакыт шәкертләр комитеты әгъзаләре белән киңәшмәләр уздырып, күрсәтмә

һәм киңәшләрен бирә.

Монда “Хөсәения” мәдрәсәсендәге кебек чикләүләр, тыюлар булмый. Беркем дә беркемне дә мәчеткә йөрергә, ураза тотарга һ.б. дини йолаларны үтәргә мәҗбүр итми. Шәкертләр дин мәсьәләләрендә һәм дини йолалар турында үз фикерләрен белдерергә хокуклы булалар.

Ләкин мәдрәсәнең матди хәле авыр була: уку биналары һәм шәкертләрнең торaклары зур булмаган агач корылмалардан гыйбарәт. Шәкертләр торагында, караватлар урынына, стеналарга ике ярусы агач койкалар беркетелгән, җиһазларга да бай булмый. Шәкертләр чисталык һәм тәртипне үзләре саклыйлар, үзләре җыештыралар. Алар өчен махсус ашханә юк. Бубый мәдрәсәсенең элекке шәкерте Габдулла Мостакаев ( Ташкент, 1966 нчы ел ) болай дип искә ала: “Без булдыра алганча туена идек, өч тапкыр ипи белән чәй эчтек, кайчакта, гадәттә, җомгаларда үзебез аш пешердек. Ипине безгә крестьян хатыннары пешерде, керләребезне дә алар юды, крестьян мунчасында юындык. Болар барысы да кечкенә генә хак бәрабәренә эшләнде. Кайбер шәкертләр крестьяннарда фатирда торып, шунда ук туендылар. Әмма андыйлар аз иде. Бу мәдрәсәдә төрле җитешсезлекләр һәм авырлыкларга карамастан, уку процессы яхшы барды, шәкертләр әйбәт шөгыльләнделәр, дус яшәделәр. Эшсез ятарга вакыт булмады, кыш һәм уку елы сизелмичә үтә иде. Спорт һәм гимнастика өчен кайбер җиһазлары булган мәйданчык бар иде”.

Әмма бу уку йорты озак яшәми. Якынча 1911 нче елның гыйнвар ахырында шәкертләр арасында хәвефле сүзләр йөри башлый, дин әһелләре мәдрәсә өстеннән патша властьларына донослар язалар икән дип сөйлиләр. Бү сүзләр, имеш - мимешләр нигезсез булмаган икән.

Февраль аенда, мәдрәсә мөдире Габдулла Бубый шәкертләр комитетының киңәйтелгән утырышында түбәндәгеләрне җиткерә: “Алдыбызда - җитди куркыныч, реакцион динчеләр хөкүмәт органнарына безнең мәдрәсә җитәкчеләре һәм мөгаллимнәре турында, имеш, без монда дингә каршы пропаганда алып барабыз, денсезләрне укытабыз һәм тәрбиялибез икән дип,

шәкертләр митинглар, әллә нинди кичәләр, җыелышлар оештыралар, тыелган әдәбият укыйлар һ.б. дип донослар язганнар. Алар, доносчылар, мәдрәсәне яптырырга, җитәкче һәм мөгаллимнәрен изоляцияләргә тырышалар; сезгә, шәкертләргә, моны хәтерегездә тотып, тыныч булырга кирәк, дәресләрдән гайре һичнинди чаралар үткәрергә кирәкми",– ди.

Һәм, чыннан да, 1911 нче елның февралендә мәдрәсә мөдирен, кайбер мөгаллимнәрне кулга алалар. Габдулла Мостакаев: "Без иртән аларның Сарапулга озатылуларын белдек. Безне, комитет әгъзаләрен, допроска чакырттылар, ләкин бездән алар берни дә ала алмадылар", - дип искә ала.

Нәтиҗәдә, төп сыйныфларда дәресләр туктый, реакцион динчеләр һәм байларның куанычына Иж - Бубый мәдрәсәсе ябыла.

**Бубый мәдрәсәсе шәкертләре.**

Әйтеп киткәнемчә, Иж - Бубый мәдрәсәсе XX гасыр башында мәгърифәт учагы була. Нәкъ менә шул мәдрәсәдә давыллы елларның каһарманнары үсеп чыгалар.

Иж - Бубый мәдрәсәсен тәмамлаган шәкертләрнең күбесе туган яктагы авылларда укытучы булып эшлиләр, балалар укыту белән шөгыльләнәләр, авыл халкына аң - белем тараталар.

Менә Даут Гобайди. Мәдрәсәне тәмамлагач, ул энесе Нәҗип белән Кыдырлыда, бабаларының абзарын көйләп, кызлар мәдрәсәсе ача. Соңыннан ул Иске Кызылъярга килә. Биредә ул үзе төзегән дәреслекләр белән малайларны да, кызларны да укыта. Дәреслекләр, фәнни - популяр әсәрләр һәм шигырьләр яза, аларны бастырып чыгара ("Шүрәле караган авыл", "Хөррият", "Төлкенең яңа хәйләсе"). Даут Гобәйди Сарсак - Омга волосте башкарма комитеты председателенең урынбасары, Советның мәгариф эшләре комиссары вазифаларын да башкара.

Колчак полкы безнең якларга ябырылып килгәч, Тәбәрле авылыннан бай Латыйп дигән кешенең хыянәте аркасында Даут Гобәйди палачлар кулына эләгә. Аны Тәбәрле зираты каршындагы юлда җәзалап үтерәләр.

Заһирә Байчурина беренче татар хатын - кыз шагыйрәләреннән санала.

Тирсә авылында туып - үсә, Буби мәдрәсәсен тәмамлый. Аның сайланма шигырьләре 1959 нчы елда басылып чыккан “Ана күзе” китабына тупланган.

Күренекле тел галиме, тәнкыйтьче, әдәбият тарихчысы Җамал Вәлиди шулай ук атаклы Иж - Бубый мәдрәсәсен тәмамлый. Башта шул ук мәдрәсәдә, ә 1911 – 1918 нче елларда “Хөсәения” мәдрәсәсендә укыта. 1918 нче елның җәендә Казанга килә, укытучылык эшен дәвам итә. Көнчыгыш педагогия институтының татар теле кафедрасы доценты була.

Кырыклап хикәя, публицистик һәм әдәбитәнкыйть мәкаләләре, тәрҗемә китаплар авторы Садри Җәләл дә 1906 – 1910 нчы елларда Буби мәдрәсәсендә укыган. Соңыннан Казандагы Татар рабфагында һәм сәнгать техникумында татар теле һәм әдәбияты укыта.

1910 нчы елда Иж - Бубый мәдрәсәсен тәмамлаган Зәйнәб Максудова да шушында ук укыта. Ул археограф, татар мәктәпләре өчен рус теле буенча дәреслекләр авторы буларак билгеле.

Балтач авылында туган Юныс Вәлиди дә Буби мәдрәсәсендә белем ала. Ул 1910 нчы елдан укытучылык эшен башкара, 1918 – 1919 нчы елларда Алабуга өязендә мөселман эшләре комиссариатының рәисе, 1920 – 1924 нче елларда Җир эшләре комиссары булып эшли.

Журналист, мәгърифәтче, педагог Ягъкуб Хәлили дә Бубыйда белем алган. 1913 – 1918 нче елларда “Сөембикә” журналының, 1917 – 18 нче елларда “Балалар дөньясы” журналының нәшире һәм мөхәррире.

“Данлыклы Буби мәдрәсәсендә белем алуым белән чиксез горурланам, - дип сөйли шәкертләрнең берсе булган Мәрьям Зәйнуллина. – Бу мәгърифәт учагы җитәкчеләре - белемле, талантлы Габдулла һәм Гобәйдулла Бубилар минем дөньяга күземне ачтылар. Бөтен хыялым алар кебек укытучылар булу иде”.

**III. Йомгаклау өлеше.**

**Шигъри күчтәнәч.** **Гөлзада Әхтәмова.** Алабуга – Исәнбай.

**Аң - белем таратучы.**

Хәтердә, халкым хәтерендә

Иж - Бубый мәдрәсәсе.

Белем учагын кабызган
Татарның аң ядрәсе.
Дин гыйлеме белән рәттән
Дөньяви белеп алып,
Шәкертләр данын таратка
Тартылган төрки халык.
Милләтенә ярдәм иткән
Азмы татар байлары?!
Ә Гобәйдулла һәм Габдулла
Габделгаллəм уллары.
Белемнең иң югарысын
Халкына бирер өчен,
Янып йөргән заманында
Кызганмый дәртен - көчен.
“Татарлар белемле була,
Татарлар калка өскә!” -
Көнләшә кара йөрәкләр,
Ошамый бу хәл һич тә.
Карар кылына беркөнне:
“Мәдрәсәне ябарга!
Аң - белемгә үрелмәсен,
Юл киселсен татарга!”.
Тарих кабатланып тора,
Үзгәрсә дә замана.
Туган халкым бу дөньяда
Күпме тапкыр алдана.
И халкым, калкып чыгасың
Ятлар батырган саен.
Аң – белемгә сусаган җан
Барыбер табар җаен.